## 3.2. Махсус саклана торган урман кишәрлекләре буенча төрләрне чикләү

Урманнарның махсус саклану кишәрлекләренең хокукый режимы Россия Федерациясе Урман кодексының 119 статьялары белән регламентлаштырыла.

Махсус саклана торган урман кишәрлекләрендә максатчыл билгеләнеше һәм файдалы функцияләре ярашмаган эшчәнлекне башкару тыела.

Махсус саклана торган урман кишәрлекләре төрләре буенча чикләү 19нчы таблицада күрсәтелгән.

19нчы таблица

Махсус саклана торган урман кишәрлекләре төрләре буенча чикләүләр

| № т/с | Урманнарның махсус саклана торган кишәрлек төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Су объектлары, чокыр сөзәклекләрендә урнашкан ярсаклагыч, туфраксаклагыч урман кишәрлекләре | Урманнарның махсус саклана торган кишәрлекләрендә түбәндәгеләрне эшләү тыела:<br>1) Россия Федерациясе Урман кодексының 21 статьясындагы 6 өлешендә каралган очраклардан тыш, урман утыртмаларын тоташ кисү һәм, әгәр сайланма кисү үзләренең мохит барлыкка китерүче, су саклау, санитария-гигиена, сәламәтләндерү һәм башка файдалы функцияләрен югалта торган урман утыртмаларын, саклык урманнарының максатчан билгеләнешен саклауны тәэмин итә торган һәм алар үти торган файдалы функцияләрне үтәүче урман утыртмаларына алмаштыруны тәэмин итә торган очраклардан тыш.<br>2) печән чабу, умартачылык һәм товар аквакультурасы (товар балыкчылыгы)ннан тыш авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнү;<br>3) линияле объектлардан һәм гидротехник корылмалардан башка, |
| 2. | Урмансыз киңлекләр белән чиктәш урман авызлары | |
| 3. | Урмансыз киңлекләр арасында урнашкан зур булмаган урман кишәрлекләре | |
| 4. | Бал бирә торган урман | |

| № т/с | Урманнарның махсус саклана торган кишәрлек төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | кишәрлекләре | капиталь төзелеш объектларын төзү һәм файдалану; |
| 5. | Дәвалау һәм сәламәтләндерү учреждениеләре тирәсендәге урман кишәрлекләре | Россия Федерациясе Су кодексына ярашлы, су саклау зоналары чикләрендә түбәндәгеләрне эшләү тыела:<br>1) туфракны ашлау өчен юынтык суларны куллану;<br>2) ziратларны, биологик калдыкларны юк итү объектларын, җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыру объектларын, химик, шартлаткыч, агулы, агулаучы һәм зәһәрле матдәләрне (диңгез портлары территорияләрендә урнашкан аммиак, метанол, аммиак селитрасы һәм калий нитратын махсус саклагычлардан тыш, аларның исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана, яр буе саклау полосалары чикләреннән тыш), радиоактив калдыкларны күмү пунктларын урнаштыру, шулай ук балыкчылык әһәмияте булган су объектлары суларында рөхсәт ителә торган иң югары концентрацияләре билгеләнмәгән пычратучы матдәләр белән территорияне пычрату;<br>3) үсемлек корткычларына һәм авыруларга каршы көрәшнең авиация чараларын гамәлгә ашыру;<br>4) транспорт чараларының (махсус транспорт чараларыннан тыш) хәрәкәте һәм туктап торуы, моңа юлларда һәм каты өслекле махсус җиһазландырылган урыннарда аларның хәрәкәте һәм туктап торулары керми;<br>5) автомобильләргә ягулык салу станцияләре, ягулык-майлау материаллары складлары төзү һәм реконструкцияләү (моңа автомобильләргә ягулык салу станцияләре, ягулык-майлау материаллары складлары портлар, эчке су юллары инфраструктурасы территорияләрендә, шул исәптән кече судноларны урнаштыру өчен базалар (корылмалар), федераль иминлек хезмәте органнары объектлары территорияләрендә урнашкан очраклардан тыш), транспорт чараларын техник карау һәм ремонтлау өчен кулланыла торган техник хезмәт күрсәтү станцияләре, транспорт чараларын юуны гамәлгә ашыру.<br>6) пестицидлар һәм агрохимикатлар саклау (яр буе саклау полосалары чикләреннән тыш диңгез портлары территорияләрендә урнаштырылган махсус саклагычларда агрохимикатлар саклаудан тыш), пестицидлар һәм агрохимикатлар куллану;<br>7) юынтык суларны, шул исәптән дренаж суларын агызу;<br>Яр буен саклау полосалары чикләрендә су саклау зоналары өчен билгеләнгән чикләүләр белән беррәттән түбәндәгеләрне эшләү тыела:<br>1) җирләрне сөрү;<br>2) юыла торган грунт өемнәрен урнаштыру;<br>3) авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү һәм алар өчен җәйге лагерьлар, су коену урыннарын ясау.<br>Урманнарның махсус саклана торган кишәрлекләрендә сайланма кисүләр бары тик корыган һәм зыян күргән урман утыртмаларын кисү максатларында гына рөхсәт ителә. |
| 6. | Шәһәр тибындагы поселоклар, авыл җирлекләре тирәсендәге урман участоклары | |

Искәрмә:
Урманнарның махсус саклана торган участокларының урнашуы һәм мәйданы урман хуҗалыгы эшләрен төзүдә проектлаштыру вакытында күрсәтелә.

## 3.3. Урманнарны файдалану төрләре буенча чикләүләр

Урманнарны файдалану төрләре буенча чикләүләр түбәндәге таблицада китерелгән.

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Үзагач әзерләү | Исәпле урман кисү күләменнән (үзагач алу өчен мөмкин булган күләм) артыграк күләмдә, шулай ук кисентеләрнең яшен бозып үзагач әзерләү тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 29 статьясындагы 5 өлеше).<br>«Россия Федерациясе Урман кодексының 23 статьясында күрсәтелгән урманчылыкларда үзагач әзерләү кагыйдәләрен һәм үзагач әзерләү үзенчәлекләрен раслау турында» 2020 елның 1 декабрендәге 993 номерлы Россия Табигать министрлыгы боерыгы нигезендә:<br>- елга һәм чишмә үзәннәрен сөйрәмә җир трассалары һәм урман юллары сыйфатында куллану рөхсәт ителми;<br>- урман кисү урыннарынан читтә, алар янәшәсендәге 50 метрлы полосада чикләрендә урман утыртмаларын, үсемчелек катлавын һәм туфракларны зарарлау, урманнарны сәнәгать һәм башка калдыклар белән пычрату рөхсәт ителми;<br>- юлларны, күперләрне һәм агач кисеп салынган юлларны, һәм шулай ук киптерүче челтәрне, юл, гидромелиоратив һәм башка корылмаларны, елга һәм чишмәләрнең су юлын саклау мөһим;<br>- өемнәрне (кисеп ташланган һәм агач кисү урырында калдырылган агачларны исәпкә алып) һәм кисеп ташланган асылынып төшкән агачларны калдыру, саклап калынырга тиешле яшь агачны зарарлау яисә юк итү тыела;<br>- чик, квартал, урман кисү урынындагы һәм башка баганаларны һәм билгеләрне юк итү яки зарарлау тыела;<br>- әлеге кагыйдәләр һәм Россия Федерациясенең урман законнары нигезендә кисү өчен билгеләнмәгән һәм сакланырга тиешле агачларны, шул исәптән орлык һәм уңыш бирә торган агачларны кисү һәм зарарлау тыела;<br>- рөхсәт ителгән вакыты (рөхсәт ителгән кичектереп торуларны исәпкә алып) тәмамланганнан соң үзагач әзерләү, һәм шулай ук файдалану хокукы туктатылганнан соң яисә тәмамланганнан соң үзагач әзерләү рөхсәт ителми;<br>- билгеләнгән вакытка (рөхсәт ителгән кичектереп торуларны исәпкә алып) үзагачны алып чыкмыйча кискән урында калдыру рөхсәт ителми;<br>и) урманнарны үзләштерү проектында яисә урман кисү эшләренең технологик картасында каралмаган урыннарга үзагачны ташу, тарттыру (транспортировкалау) рөхсәт ителми; |

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | - урман кисү калдыкларыннан (агачларны аударганда һәм ташыганда (транспортировкалаганда), шулай ук кәүсәләрне киселгән агачларның очларын, ботакларын, чыбыкларын чистартканда калган агач калдыкларыннан) чистарту эшләрен үтәмәү яисә үз вакытында үтәмәү рөхсәт ителми;<br>- төяү мәйданнары һәм сөйрәмә җирләрдән кала туфракның өске уңдырышлы катламын юк итү рөхсәт ителми.<br>Урман кисү урыннарында үзагач әзерләгәндә яшәргә яраклы, аларның табигый ареалы чикләрендә үсеп китүче (әгәр дә тиешле агач токымының урманнар составындагы мәйданы өлеше урманчылык мәйданының 1 процентыннан артып китмәсә) кыйммәтле агач токымнарын (имән, бүк агачы, корычагач, эрбет, юкә, күгагач, элмә агачы, кара зирек, чәчә торган каштан) кисү рөхсәт ителми.<br>Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән төрләр сакланырга тиеш.<br>Үзагач әзерләгәндә урман утыртмалары агачлары составында 3 һәм аннан да күбрәк берәмлектә эрбет булган өлгергән, картайган урман утыртмаларын кисү рөхсәт ителми. |
| 2. | Чәер әзерләү | «Чәер әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 911 номерлы Россия Табигать министрлыгы боерыгы нигезендә түбәндәгеләргә кирт салу рөхсәт ителми:<br>- зарарлы организмнарны юкка чыгарганчы чыганаклардагы урман утыртмаларына;<br>- урман янгыннары, зарарлы организмнар һәм башка тискәре факторлар нәтиҗәсендә зарарланган һәм зәгыйфьләнгән урман утыртмаларына;<br>- Россия Федерациясе законнары нигезендә үзагач әзерләү максатында өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын тоташ яки сайланма кисүләр рөхсәт ителмәгән урманнардагы урман утыртмаларына;<br>- даими урман - орлык кишәрлекләрендә, орлык плантацияләрендә, генетик тыюлыкларда урнашкан урман утыртмаларына, шулай ук уңыш бирә торган агачлар, орлык агачлары, орлык чәчәклекләре һәм полосалары урнашкан урман утыртмаларына. |
| 3. | Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу | Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу өчен үсемлекләрнең түбәндәге төрләрен куллану тыела:<br>- Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән;<br>- наркотик чаралар дип танылган;<br>- үзагачын әзерләү рөхсәт ителмәгән агачларның һәм куакларның төрләре (токымнары) исемлегенә кертелгән.<br>Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу чикләнергә яки радиоактив матдәләр белән пычранган районнарда билгеләнгән тәртиптә тыелырга мөмкин.<br>«Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 июлендәге 496 номерлы Россия Табигать министрлыгы боерыгы нигезендә: |

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | - эрозиягә каршы урманнарда; су объектлары, чокыр авышлыклары буйларында урнашкан ярсаклагыч һәм туфраксаклагыч урман кишәрлекләрендә, фәнни яки тарихи әһәмияткә ия урманнарда, шулай ук тулылыгы 0,8- 1,0 булган яшь агачларда һәм ябалдашы тоташмаган урман культураларында түмәр сагызын әзерләү рөхсәт ителми.<br>– агачларны туз әзерләү өчен кисү тыела;<br>– Әзерләнгән урман продукциясенең сыйфаты кимүгә китергән агач һәм куак кайрысын әзерләү рөхсәт ителми;<br>– агачларны һәм куакларны, аларның очларын, ботакларын һәм чыбыкларын сындыру, чыбык-чабык әзерләгәндә үсеп утыра торган агачларның ботакларын һәм очларын кисү рөхсәт ителми;<br>– табигый һәм башка объектларны саклау функциясен башкарган урманнарда, су саклау зоналарында урнашкан урманнарда, кыйммәтле урманнарда урман түшәмәсе җыю тыела;<br>– тәҗрибә һәм эксперименталь кисүләр үткәргәндә минек бәйләү, себерке һәм үрү өчен ботаклар һәм куаклар әзерләү, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен тапшырылган урманнарда даими сынау мәйданнарында югары сыйфатлы агачлар сайлап алу рөхсәт ителми;<br>– тәҗрибә һәм эксперименталь кисүләр үткәргәндә агачның яшеллеген җыю, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен тапшырылган урманнарда даими сынау мәйданнарында югары сыйфатлы агачларны сайлап алу рөхсәт ителми. |
| 4. | Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу | Төрләре Кызыл китапка, Татарстан Республикасы кызыл китабына кертелгән яки наркотик матдәләр булып саналган гөмбәләрне һәм кыргый үсүче үсемлекләрне әзерләү һәм җыеп алу рөхсәт ителми.<br>Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу радиоактив матдәләр белән пычранган районнарда билгеләнгән тәртиптә чикләнергә мөмкин.<br>«Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үсемлекләрен җыю кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 июлендәге 494 номерлы Россия Табигать министрлыгының боерыгы нигезендә:<br>- җимеш бирә торган агачларны кисү һәм җимешен җыю өчен ботакларын кисү тыела.<br>- чикләвек җыйганда агачларны һәм куакларны кисү, шулай ук агачларны һәм куакларны зарарлый торган ысулларны куллану тыела.<br>- гөмбә җыю да аларның ресурсларын саклауны тәэмин итүче ысуллар белән башкарылырга тиеш;<br>- каен суын әзерләү өлгергән урман кишәрлекләрендә кисәренә 5 елдан да ким булмаган вакыт кала рөхсәт ителә.<br>- башка азык-төлек ресурсларын әзерләү аларның куаклыклары торышын начаратмый торган ысуллар белән башкарылырга тиеш;<br>үсемлекләрне тамырлары белән өзеп алырга, яфракларын (вайаларын) һәм тамырларын зарарлау тыела. |
| 5. | Аучылык | Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру |

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен башкару | тыела:<br>- урман-парк зоналарында урнашкан урманнарда (Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты).<br>- әгәр әлеге эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру урман утыртмаларын кисүгә яисә аучылык инфраструктурасы объектларын булдыруга китерсә, яшел зоналарда урнашкан урманнарда (Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясындагы 4 өлешенең 4 пункты). |
| 6. | Авыл хуҗалыгын алып бару | Су саклау зоналарында урнашкан урманнарда, печән чабудан, умартачылыктан һәм товар аквакультурасыннан (товар балыкчылыгыннан) тыш, авыл хуҗалыгы алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 113 статьясындагы 2 өлеше).<br>Яр буен саклау полосалары чикләрендә җирләрне сөрү, авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү һәм алар өчен җәйге лагерьлар, коену урыннары ясау тыела (Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясындагы 17 өлешенең 1, 3 пунктлары белән).<br>Урман-парк зоналарында урнашкан урманнарда авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнү тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясындагы 2 өлешенең 3 пункты).<br>Яшел зоналарда урнашкан урманнарда, печән чабудан һәм умартачылыктан тыш, авыл хуҗалыгы алып бару, шулай ук печән чабу һәм умартачылык максатларында киртәләр тоту тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясындагы 4 өлешенең 2 пункты).<br>Тыюлы урман кишәрлекләрендә авыл хуҗалыгы алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 119 статьясындагы 3 өлешенең 3 пункты)<br>Урманнарның аерым саклана торган участокларында авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнү тыела, ләкин печән чабу һәм бал корты асрау гамәлләре рөхсәт ителә (Россия Федерациясе Урман кодексының 119 статьясындагы 4 өлешенең 2 пункты).<br>«Авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен һәм урман кишәрлеген бирмичә, сервитут, гавами сервитут билгеләп яисә билгеләмичә авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалану исемлеген раслау турында» 2020 елның 2 июлендәге 408 номерлы Россия Табигать министрлыгы боерыгы нигезендә:<br>- урман культуралары, кыйммәтле агач токымнарының табигый яшь үсентеләре, үсеп китәргә сәләтле яшь агачлыкларда терлек көтү рөхсәт ителми;<br>- селекция-урман орлыгы, нарат, чыршы-ак чыршы, тал, каты яфраклылар, чикләвекле плантацияләр кишәрлекләрендә терлекләр көтү рөхсәт ителми;<br>- табигый урман торгызуга һәм ылыслы һәм каты яфраклы агач токымнары белән урман үрчетүгә ярдәм итү буенча проектлана торган чаралар булган кишәрлекләрдә терлекләр көтү тыела;<br>- җиңел юыла торган һәм тарала торган туфраклы участокларда авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү рөхсәт ителми. |

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану максатларында урман фондының кыйммәтле агач токымнарының табигый яшь үсентеләре, селекция-урман орлыклары, нарат, чыршы, каты яфраклы, чикләвек плантацияләре булган, табигый урман торгызу һәм ылыслы һәм каты яфраклы токымнар белән урман торгызу проектлана торган чаралы, җиңел юыла торган һәм тарала торган туфраклы җирләрне файдалану тыела.<br>Авыл хуҗалыгы хайваннарын (киртәләнгән кишәрлекләрдә яисә бәйләвечтә көтүдән тыш) көткәндә урман культураларын, питомникларны, табигый яшь үсентеләрне һәм урманның башка кыйммәтле кишәрлекләрен таптауны булдырмау тәэмин ителергә тиеш. |
| 6.1 | Һәвәскәр балыкчылыктан тыш, балык үрчетүне гамәлгә ашыру | Балыкчылыкны гамәлгә ашырганда, һәвәскәр балык тотудан тыш, рөхсәт ителми:<br>- бирелгән урман кишәрлегеннән читтә урман утыртмаларына, үсемлекләр капламына һәм туфракка зыян салу;<br>- бирелгән урман кишәрлеген һәм аннан читтәге территорияне төзелеш һәм көнкүреш чүп-чарлары, агач калдыклары белән пычрату;<br>- бирелгән урман кишәрлеге мәйданының һәм аннан читтәге территориянең химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату. |
| 7. | Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, белем бирү эшчәнлеген алып бару | «Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 27 июлендәге 487 номерлы Россия Табигать министрлыгы боерыгы нигезендә:<br>- бирелгән урман кишәрлегеннән читтә урман үсентеләрен, үсемлекләр капламын һәм туфракны зарарлау;<br>- бирелгән урман кишәрлеген һәм аннан читтәге территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән пычрату;<br>- бирелгән урман кишәрлеге һәм аннан читтәге мәйданнарны химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату. |
| 8. | Рекреация эшчәнлеген башкару | «Рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 908 номерлы Россия Табигать министрлыгы боерыгы нигезендә:<br>- Рекреация эшчәнлеген башкаруга бирелгән урман кишәрлекләрендә табигый ландшафтлар, хайваннар дөньясы объектлары, үсемлекләр дөньясы, су объектлары сакланырга тиеш;<br>- Россия Федерациясе Кызыл китабына яисә Россия Федерациясе субъектының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган агачларны, куакларны, лианалар, башка урман үсемлекләрен саклау мөмкин булмаган очракта, рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану рөхсәт ителми;<br>- физик затларның яшәү урыннары булган объектларны урнаштыру рөхсәт ителми;<br>- ял итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану әйләнә-тирә мохиткә һәм кеше сәламәтлегенә зыян китерми торган |

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | ысуллар белән гамәлгә ашырыла.<br>Капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау өчен урман утыртмаларын тоташ кисү рөхсәт ителми (Россия Федерациясе Урман кодексының 21 статьясындагы 4 өлеше).<br>Федераль законнар нигезендә торак йортларга кертелгән капиталь төзелеш объектларын төзү һәм эксплуатацияләү рөхсәт ителми (Россия Федерациясе Урман кодексының 21 статьясындагы 11 өлеше). |
| 9. | Урман плантацияләрен булдыру һәм аларны файдалану | Су саклау зоналарында урнашкан урманнардан файдалану тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 113 статьясындагы 3 пункты).<br>«Урман орлыкчылыгы объектларын (урман-орлык плантацияләрен, даими урман-орлык кишәрлекләрен һәм башка урман утыртмаларын, урман үсемлекләре орлыкларын, үсентеләрне, урман агач токымнары чәчкеннәрен җитештерү (үстерү, җыю), шулай ук урман үсемлекләренең генофондын саклап калу һәм нәселдәнлек үзлекләрен өйрәнү максатларында кулланыла торган урман үсемлекләрен) төзү һәм бүлеп бирү, мондый объектларны карау кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 25 апрелендәге 231 номерлы Россия Табигать министрлыгының боерыгы нигезендә уңдырышсыз утыртмаларда уңдырышлы агачларны сайлап алу рөхсәт ителми. |
| 10. | Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үсемлекләрен үстерү | «Урман җиләк-җимеш, декоратив үсемлекләр, дару үсемлекләре үстерү өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 июлендәге 497 номерлы Россия Табигать министрлыгы боерыгы нигезендә:<br>- җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен, беренче чиратта, урман фонды җирләре составындагы урмансыз җирләр, һәм шулай ук урман булып китмәгән кисенте урыннары, аланнарны һәм аларга урман культураларын утыртканчы урманның табигый торгызылуы мөмкин булмаган башка урман үсемлекләре белән капланмаган җирләр, рекультивацияләнергә тиешле (эшләнелгән торфлыклар) җирләр файдаланыла;<br>- җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен реконструкцияләүгә билгеләнмәгән азкыйммәтле утыртма кишәрлекләре файдаланырга мөмкин. |
| 10.1 | Урман питомникларын булдыру һәм аларны файдалану | «Урман питомникларын төзү һәм алардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 12 октябрендәге 737 номерлы Россия Табигать министрлыгы боерыгы нигезендә:<br>- урман питомникларында үсентеләр, чәчкеннәр үстерү өчен үсеп китүләре һәм башка сыйфатлары тикшерелмәгән урман үсемлекләре орлыкларын куллану рөхсәт ителми;<br>- урман питомникларында урман үсемлекләре орлыкларының партияләрен аерым чәчү кулланыла; урман үсемлекләре орлыкларының партияләрен катнаштыру рөхсәт ителми;<br>- урман питомникларын төзү һәм алардан файдалану өчен урман белән капланмаган җирләрдән файдаланалар;<br>- Россия Федерациясе Кызыл китабына яисә Россия Федерациясе |

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | субъектының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган агачларны, куакларны, лианалар, башка урман үсемлекләрен саклау мөмкин булмаган очракта урманнарда урман питомникларын төзү һәм алардан файдалану рөхсәт ителми;<br>- Россия Федерациясе Кызыл китабына, Россия Федерациясе субъектларының Кызыл китапларына кертелгән үсемлек төрләре очрый торган урман кишәрлекләреннән урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен файдалану Россия Федерациясе Урман кодексының $60^{15}$ статьясы нигезендә тыела. |
| 11. | Геологик тикшеренүләр үткәрү, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару | Яшел зоналарда һәм урман-парк зоналарында урнашкан урманнарда урнашкан урманнарда (Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясындагы 2 өлешенең 4 пункты, 4 өлешенең 1 пункты) файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару тыела.<br>Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмалар табу һәм чыгару максатларында урманнардан файдаланганда рөхсәт ителми:<br>- бульдозер ярдәмендә агачларны аудару һәм урман кишәрлекләрен агач үсемлекләреннән чистарту, чик буе полосаларын һәм урман авызларын агач калдыклары белән пычрату, урман авызындагы агачларның кәүсәләрен һәм скелет тамырларын зарарлау, җәйге чорда урманда киселгән агач материалын Россия Федерациясе Урман кодексында билгеләнгән тәртиптә расланган урманнарда санитар куркынычсызлык кагыйдәләре нигезендә кәүсә корткычлары ияләшүдән саклау чараларын күрмичә калдыру (саклау);<br>- урман утыртмаларын суга батыру һәм озак итеп су бастыру;<br>- бирелгән урман кишәрлеге чигендәге урман үсентеләрен, үсемлекләр капламын һәм туфракны зарарлау;<br>- урманнарны эшкәртү һәм көнкүреш калдыклары белән пычрату;<br>- бирелгән урман кишәрлеге мәйданын һәм аннан читтәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;<br>- транспорт чараларының һәм башка механизмнарның ирекле, билгесез маршрутлар буенча, шул исәптән урманнардан файдаланыла торган җирләрдән читтә йөрүе (Файдалы казылмаларны геологик өйрәнүне, разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану кагыйдәләренең 18 пункты һәм җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, урман кишәрлеге бирелмичә генә файдалы казылмаларны разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыру максатларында сервитут билгеләп яисә билгеләмичә «Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, файдалы казылмаларны разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен һәм җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, файдалы казылмаларны разведкалауны һәм чыгаруны урман кишәрлеге бирмичә, сервитут билгеләп яисә билгеләмичә гамәлгә ашыру максатларында урманнардан файдалану очраклары Исемлеген раслау турында» Россия Табигать министрлыгының 2020 елның 7 июлендәге 417 номерлы боерыгы белән расланган урманнардан файдалану очраклары исемлеге). |

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | Федераль законнар нигезендә торак йортларга кертелгән капиталь төзелеш объектларын төзү һәм эксплуатацияләү рөхсәт ителми (Россия Федерациясе Урман кодексының 21 статьясындагы 11 өлеше). |
| 11.1 | Эзләнү эшчәнлеген гамәлгә ашыру | «Эзләнү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2024 елның 25 апрелендәге 241 номерлы Россия Табигать министрлыгы боерыгы нигезендә рөхсәт ителми:<br>-урманнардан файдаланыла торган җирләрдән читтә урман утыртмаларына, үсемлекләр катламына һәм туфракка зыян салу;<br>- урманнардан файдалана торган территорияләрне һәм урманнардан файдалана торган җирләргә якын территорияләрне җитештерү һәм көнкүреш калдыклары белән пычрату;<br>- урманнардан файдаланыла торган җирләрне һәм урманнардан файдаланыла торган җирләргә якын территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;<br>- транспорт чараларының ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буенча, шул исәптән урманнардан файдаланыла торган җирләрдән читтә йөрүе. |
| 12. | Гидротехник корылмалар, шул исәптән сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектлары барлыкка китерүче корылмалар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү, сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектларын урнаштыру, диңгез һәм елга портлары территорияләрен булдыру һәм киңәйтү | Федераль законнар нигезендә торак йортларга кертелгән капиталь төзелеш объектларын төзү һәм эксплуатацияләү рөхсәт ителми (Россия Федерациясе Урман кодексының 21 статьясындагы 11 өлеше). |
| 13. | Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм файдалану | «Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен һәм линияле объектлар төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү өчен урман кишәрлеге бирмичә, сервитут, гавами сервитут билгеләп яисә билгеләмичә урманнардан файдалану очраклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 10 июлендәге 434 номерлы Россия Табигать министрлыгы боерыгы нигезендә рөхсәт ителми:<br>- урманнардан файдаланыла торган җирләрдән читтәге урман утыртмаларына, үсемлекләр катламына һәм туфракка һәм линия |

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | объектларының саклау зонасына зыян салу;<br>- урманнардан файдаланыла торган җирләргә якын территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш чүп-чарлары, агач калдыклары белән пычрату;<br>- урманнардан файдаланыла торган җирләрне һәм урманнардан файдаланыла торган җирләргә якын территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;<br>- транспорт чараларының, механизмнарның билгеләнмәгән ирекле маршрутлар буенча йөрүе.<br>Федераль законнар нигезендә торак йортларга кертелгән капиталь төзелеш объектларын төзү һәм эксплуатацияләү рөхсәт ителми (Россия Федерациясе Урман кодексының 21 статьясындагы 11 өлеше).<br>Урман-парк зоналарында урнашкан урманнарда, велосипед һәм йөгерү юлларыннан һәм гидротехник корылмалардан тыш, капиталь төзелеш объектлары төзү тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясындагы 2 өлешенең 5 пункты).<br>Яшел зоналарда урнашкан урманнарда, гидротехник корылмалардан, элемтә линияләреннән, электр тапшыру линияләреннән, җир асты торба үткәргечләреннән тыш, капиталь төзелеш объектларын төзү һәм алардан файдалану тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясындагы 4 өлешенең 3 пункты). |
| 14. | Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын төзү һәм алардан файдалану | «Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 31 гыйнварындагы 54 номерлы Россия Табигать министрлыгы боерыгы нигезендә урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдаланганда түбәндәге очраклар булдырылмаска тиеш:<br>- урманнарның пычрануы (шул исәптән радиоактив һәм нефть) һәм урманнарга башка тискәре йогынтысы;<br>- гражданнарның урманнарда булуына чикләүләр кертелгән очракта, урман кишәрлекләренә транспорт чаралары керү.<br>Саклык урманнарында, шулай ук РФ Урман кодексында, башка федераль законнарда каралган очракларда урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру һәм эксплуатацияләү тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 14 статьясындагы 2 өлеше).<br>Капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау өчен урман утыртмаларын тоташ кисүләр рөхсәт ителми (Россия Федерациясе Урман кодексының 21 статьясындагы 4 өлеше).<br>Федераль законнар нигезендә торак йортларга кертелгән капиталь төзелеш объектларын төзү һәм эксплуатацияләү рөхсәт ителми (Россия Федерациясе Урман кодексының 21 статьясындагы 11 өлеше). |
| 15. | Дини эшчәнлек алып бару | Капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау өчен урман утыртмаларын тоташ кисү рөхсәт ителми (Россия Федерациясе Урман кодексының 21 статьясындагы 4 өлеше).<br>Федераль законнар нигезендә торак йортларга кертелгән капиталь |

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | төзелеш объектларын төзү һәм эксплуатацияләү рөхсәт ителми (Россия Федерациясе Урман кодексының 21 статьясындагы 11 өлеше). |

20нче таблица

## Урман кисү эшләрен башкарганда сакланырга тиешле биологик төрлелек объектларының һәм буфер зоналарының нормативлары һәм параметрлары

| № т/с | Биологик төрлелек объектларының атамасы | Биологик төрлелек объектларының характеристикасы | Буфер зоналарының үлчәмнәре (кирәк булганда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Даими һәм вакытлы су агу юлы | Су агымының юлын аермачык күреп була. Вакытлыча су агымы вакытлыча су басу эзләреннән ачыкланырга мөмкин. Су агу юлы коры җәйдә кибәргә мөмкин | Әгәр нормативларда башкасы билгеләнмәсә, даими су агу юлы өчен киңлеге 50 м дан да ким булмаган буфер зонасы, вакытлы су агу юлы үзәне буйлап - 20 м дан да ким булмаган буфер зонасы бүлеп бирелә. Буфер зонасы инде урманлы тугай булырга тиеш түгел һәм һәр яктан су агымы үзәненнән яисә урмансыз тугайдан үлчәнә. Искәрмә: буфер зонасына текә сөзәклекләр һәм төп токымнарның чыгу урыннары кертелергә тиеш |
| 2. | Чыганаклар (чишмәләр), грунт сулары чыгу урыннары | Төптә чишмәләр күренергә мөмкин, яисә су тау битендә чыганак рәвешендә агып чыгарга мөмкин. Чыганак карст аралыгыннан агып чыгарга мөмкин. | Чыганаклар (чыгып торган урыннары) тирәсендә киңлеге кимендә 50 м булган буфер зона аерылып тора. Дәвалау яисә сәламәтләндерү максатларында кулланыла торган, шулай ук табыну объекты (Изге чишмәләр) булган чыганаклар тирәсендә буфер зонасы киңәйтелергә мөмкин - индивидуаль тәртиптә билгеләнә |
| 3. | Сазлыклы түбәнлекләр һәм вакытлыча су басу участоклары | Участок артык дымлы: су өстә җыелып тора яки аяк белән басканда чыгып тора. Объект чикләрендә-артык дымлы типтагы урманнарның туфрак капламы. Кырыйда, шулай ук объектлар | Су баскан участок кырыенда (су өстә тора яки басканда чыга). Рельефтагы түбәнәю буенча, чик туфрак капламында, чик буенча |

| № т/с | Биологик төрлелек объектларының атамасы | Биологик төрлелек объектларының характеристикасы | Буфер зоналарының үлчәмнәре (кирәк булганда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | чикләрендә агачлык юк яисә товарлыгы түбәнрәк агачлардан тора | туфрак капламы һәм агачлык характерында. |
| 4. | Күл, сазлык һәм башка ачык участоклар ярлары буендагы урманнар, сазлыклардагы кечкенә утраулар | Ачык җирләр (күлләр, сазлыклар, болыннар) ярлары буйлап урман кырыен аерып чыгару урман төзелеше тарафыннан яклау полосасы бүленмәгән очракта башкарыла | Киңлеге 50 м дан да ким булмаган урман чите күлнең яисә башка ачык участокның суы киселешеннән үлчәнә. Ләкин күлдә эретмә яки сазлыклы кырый булса, буфер зонаны каты Яр кырыеннан яки сазлык кырыеннан яки ачык территориядән үлчиләр. Шулай ук сазлык белән әйләндереп алынган кечкенә утраулар (мәйданы 0,5 гектарга кадәр) аерылып тора. Искәрмә: Искәрмә: әгәр бу күл яки сазлык хайваннарның сезонлы туплану һәм үрчү урыны, сирәк һәм зәгыйфь төрләрнең фактик яшәү урыны булса, буфер зонасы киңәйтелергә тиеш. |
| 5. | Чокырлар, тирән су агымы үзәннәре, башка текә сөзәклекләр | Су агымнары үзәннәре һәм чокырлар - битләүләрнең текәлеге 10°булганда. Башка текә битләүләр (калкулыклар, ярлар) - битләүләрнең текәлеге кимендә 20°булганда | Әгәр нормативларда башкасы билгеләнмәсә, тау түбәсе һәм тау итәге буйлап киңлеге 15-20 м дан да ким булмаган буферлы зоналар аерылып чыга. Төп объект булып тау бите үзе һәм буферлы зона тора. |
| 6. | Төп токымнарның ачылып торуы, шул исәптән сельгалар, чыганаклары известь булган токымнар, ачык комлы участоклар, дюналар, ташлы сибелмәләр | Калын булмаган туфрак-үсемлек капламы булган, төп токымнар күренә торган участоклар. Ташлы сибелмәләр - төрле зурлыктагы һәм әйләнмәле таш тупланмалары. Еш кына тау битләрендә, калкулыкларда, текә ярларда һәм алар янында очрый. Ташлы сибелмәләр һәм ачылып торган тау токымнары бераз туфрак-үсемлекләр белән капланырга мөмкин. Ком дюналары өлешчә калын булмаган туфрак-үсемлек капламы белән беркетелергә мөмкин | Объект җирле токымнар ачыкланган кишәрлек чиге буйлап яисә коелган җир чиге буйлап аерылып чыга. Чәчелгән җирдән, төп токымнарның ачылуыннан, дюна комплексыннан киңлеге кимендә 20 м булган буфер зонасы аерылып чыга. |
| 7. | Аерым эре ташлар һәм кыялар | Лишайниклар һәм үсемлекләр белән капланган аерым эре ташлар (2 куб метрдан башлап) һәм кыялар | Аерым эре ташларны мәйдан объектын аермыйча билгеләп була, аларның тупланмалары мәйдан объекты буларак билгеләнә |

| № т/с | Биологик төрлелек объектларының атамасы | Биологик төрлелек объектларының характеристикасы | Буфер зоналарының үлчәмнәре (кирәк булганда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 8. | Карст элементлары | Ярыклар, аралыклар, төшеп югала торган су юллары һәм сулыклар, известьлы токымнар өслегенә якын җирләрдә коры сазлыклар. Известьташ катламындагы су белән юылган куышлыклар. Өслектә түбәнлекләр, упкыннар, ярыклар кебек күренәләр. Чыганаклар, төп сазлыклар карст элементлары белән бәйле булырга мөмкин. Өслектә известьташларның ачылып торуы күренергә мөмкин | Объект тирәсендә түбәнәю читеннән, куышлыклардан кимендә 20 м киңлектәге буфер зона бүлеп чыгаралар |
| 9. | Ачык һәм ярым ачык участоклар | Урман белән капланмаган участоклар: зур булмаган ачыклыклар, сирәк урманнар (шул исәптән сазлыклы), болынлыклар һ.б. Агачлык тулылыгы 0,4 тән түбән. Запас 50 куб. метр/гектардан түбән | Чик буйлап агачлык (тулылыгы түбән һәм запасы аз булган участок) |
| 10. | Ауган өемнәр һәм җил-туфрак комплекслары белән таркалу урыннары | Төрле токымлы, таркалуның төрле стадияләрендә эре аву урыннары (диаметры 20 сантиметрдан (алга таба - см)). Җил-туфрак комплекслары (ВПК) - тамыр системасы һәм туфракның өске катламнары белән бергә эре агачларның авуы нәтиҗәсе | Табигый яңарыш төркемнәре, шулай ук башка объектлар белән бергә таркалу урыннарын аерып алу максатка ярашлы. Бүлеп бирү объект чиге буйлап үткәрелә |
| 11. | Коры-сары, биек агач төпләре, куышлы агачлар, берәм-берәм ауган эре агачлар | Төрле токымлы эре үлчәмле коры-сары (диаметры 20 см дан). Куышлыклары һәм тукран эшчәнлеге эзләре булган коры-сары агач аеруча кыйммәтле. Биеклеге 2-5 м һәм диаметры 20 см дан артык булган табигый эре төпчекләр. куышлы агачлар. Төрле токымлы, таркалуның төрле стадияләрендәге булган эре аунаган агачлар (диаметры 20 см дан) | Урман кисүне эшләгәндә куркыныч тудырмый торган коры-сарыны саклау максатка ярашлы. Куышлы корыган һәм исән агачлар һичшиксез сакланырга тиеш |
| 12. | Картайган агачлар һәм аларның бушлыклары, компактлы биологик кыйммәткә ия кишәрлекләр | Аерым утырган зур картайган агачлар, аларның бушлыклары һәм тыгыз биологик кыйммәтле участоклар | Бигрәк тә янгын сүндерүче киптерүче карт яшь наратлар, карт усак, кара зирек, кәҗә талы әһәмиятле. Агачларның яхшы үсеш алган ябалдашлары булырга һәм җилгә тотрыклы булырга тиеш. Агачларны иске агачлар түтәлендә һәм компактлы биологик кыйммәткә ия участоклар составында саклап калу оптималь булып тора |
| 13. | Төбәк өчен сирәк | Киң яфраклы агачлар: имән, корычагач, | Сирәк токымлы агачларның |

| № т/с | Биологик төрлелек объектларының атамасы | Биологик төрлелек объектларының характеристикасы | Буфер зоналарының үлчәмнәре (кирәк булганда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | токымлы агачлар | карама, өрәңге, юкә | компакт төркемнәрен һәм бу токымнарның берәмлек агачларын үз эченә алган түтәлләр саклана |
| 14. | Сирәк һәм азык куаклары | Чикләвек куагы, гади артыш, миләш, гөлҗимеш, артыш, зелпе куаклары һ. б. | Агач сөйрәтү юлларыннан читтә саклана |
| 15. | Гамәлдәге яңарту төркемнәре | Агач кисү урыннарында үсә алырлык ышанычлы үсмер агачлар төркеме. Дренажланган кишәрлекләрдәге агач катламы ачыклыкларында яңарту төркемнәре, эре ауган өемнәрдән үсүче чыршы үсентеләре | Үсә торган агач түтәлләре е яңартуның югары тыгызлыгы чиге буенча аерылып тора |
| 16. | Үсемлекләрнең һәм гөмбәләрнең сирәк һәм зәгыйфь төрләренең үсү урыннары | Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм/яки төбәк Кызыл китабына кертелгән үсемлекләрнең һәм гөмбәләрнең сирәк һәм зәгыйфь төрләренең яңа ачыкланган даими үсү урыннары | Төрләрнең биологиясе һәм экологик таләпләре нигезендә аерылып торалар. Күп кенә сирәк төрләрне билгеләү авыр булганлыктан, сирәк төрнең булуын һәм аларны саклау өчен кирәкле участокның чикләрен ачыклау өчен биолог-белгечкә мөрәҗәгать итәргә киңәш ителә. Әгәр бер генә нөсхә яки затларның җыйнак төркеме ачыкланса, алар тирәсендә киңлеге 50 м дан да ким булмаган буфер зонаны аерып күрсәтергә кирәк. |
| 17. | Куышлы агачлар | Куышлы ялгыз үсә торган яки корыган агачлар | Җилгә чыдамлыкны тәэмин итү өчен аерым агачлар яки агачлар төркемнәре, бөҗәк ашаучы кошлар яши торган урыннар, шулай ук башка кыйммәтле объектлар составында сакланалар |
| 18. | Зур оялы агачлар | Зур оялы агачлар саклана, диаметры 1 м дан артык булган оялары, шулай ук эре оялар тупланган урыннары аеруча кыйммәтле. | Диаметры 1 м һәм аннан да артыграк булган оялар өчен буфер зонаның киңлеге 500 м (елның теләсә кайсы вакытында), калган оялар өчен 100-300 м дан да ким булмаска тиеш (кошның фаразланган төренә карап). Буфер зонасының күләме белгеч-орнитолог тарафыннан тикшерү нәтиҗәләре, ояның нәрсәнеке булуын һәм аның статусын билгеләү буенча |

| № т/с | Биологик төрлелек объектларының атамасы | Биологик төрлелек объектларының характеристикасы | Буфер зоналарының үлчәмнәре (кирәк булганда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | төгәлләштерелергә мөмкин |
| 19. | Эре кырмыска оялары | Биеклеге 0,5 м дан арткан кырмыска оялары | Биеклеге 0,5 м дан арткан кырмыска оялары тирәсендә 20 м радиуста кисү тыелган буфер зонасы бүлеп бирелә |

Гамәлдәге урман орлыкчылыгы объектларының нормативлары һәм параметрлары әлеге урман хуҗалыгы регламенты белән билгеләнми.